# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛБӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАРЫ

«11» апрель 2025 ел № 140/1

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл Илбәк җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 16 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә, түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

Илбәк ав., А. Вәлиев ур., 50 й. (административ бина),
Илбәк ав., А. Вәлиев ур., 10А йорт (торак йорт янында),
Ирекле авылы, Подгорная ур. (мәгълүмат стенды),
Тархан ав., Урман ур., 2 й. (мәгълүмат стенды),
Тырыш Бистәсе, Октябрьнең 70 еллыгы ур., 1нче йорт (мәгълүмат стенды).

3. Карар ул басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Рәис Р.К.Галимҗанова

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге советы карарына 1 нче кушымта
11.04.2025 № 140/1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен
бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № | сайлау округы исеме | Округ чиге | сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Илбәк № 1 | **Илбәк ав.**<br>Ә. Вәлиев ур., 1 нче йорттан алып 21 нче йортка кадәр, 52,60 нчы йорт | 34 |
| 2 | Илбәк № 2 | **Илбәк ав.**<br>Ә. Вәлиев ур., 25 нче йорттан алып 31 нче йортка кадәр, 36 нчы йорттан алып 44 нче йортка кадәр, 51, 61 нче йорт | 31 |
| 3 | Илбәк № 3 | **Илбәк ав.**<br>Ә. Вәлиев ур., 33 нче йорттан алып 35 нче йортка кадәр, Профсоюз ур. | 29 |
| 4 | Илбәк № 4 | **Илбәк ав.**<br>Кооперативная ур. | 33 |
| 5 | Илбәк № 5 | **Ирекле ав.**<br>**Илбәк ав.** Ә. Вәлиев ур., 45 нче йорттан алып 50 нче йортка кадәр | 31 |
| 6 | Илбәк № 6 | **Тархан ав.**<br>**Тырыш бист.**<br>Октябрьнең 70 еллыгы ур., 72 нче йорттан алып 82 нче йортка кадәр | 33 |
| 7 | Илбәк № 7 | **Тырыш бист.**<br>Октябрьнең 70 еллыгы ур., 1 нче йорттан алып 70А йортына кадәр | 34 |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге советы карарына 2 нче кушымта
11.04.2025 № 140/1

